ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 август 2024 ел № 5325

Башкарма комитетның 2022 елның 24 июнендәге 3213 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясен төзекләндерүгә бәйле җир эшләрен оештыру һәм үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы Карары, Шәһәр Уставының 41 статьясындагы 4 өлешенең 15 пунктчасы, 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 24 июнендәге 3213 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясен төзекләндерүгә бәйле җир эшләрен оештыру һәм үткәрү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 26 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 3, 4 пунктчалар өстәргә:

«3) подрядчы (эшләр башкаручы) булмаган очракта, ордерда күрсәтелгән срокларда, билгеләнгән тәртиптә ордерны ябарга;

4) эш башкаручылар (подрядчылар) тарафыннан сроклар үтәлешен контрольдә тотарга.»;

2) 35 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«35. Элек алынган ордер буенча җир эшләрен башкарганнан соң бозылган урыннарны торгызу буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яисә заказчы, подрядчы (эшләр башкаручы) системалы рәвештә (ике тапкыр рәттән) производство кагыйдәләрен һәм срокларын, шулай ук ордерны ябу буенча бурычларны үтәмәгән очракта, заказчыга һәм подрядчыга (эшләр башкаручыга) җир эшләрен башкаруга рөхсәт бирүдән баш тартыла.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов